Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLV-10**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 24 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 15 декабрендәге XIV-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазифасын алмаштыруга конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге “Россия Федерациясе дәүләт гражданнар хезмәтенең вакантлы вазифасын алмаштыруга конкурс турында” 112 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 15 декабрендәге XIV-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазифасын алмаштыруга конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә (2019 елның 22 июлендә XLIV- 3 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8, 8.1 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8.Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы конкурс комиссиясенә тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган форма буенча тутырылган һәм кул куелган анкета фотография белән;

в)паспорт яки аны алыштыручы документның күчермәсе (тиңдәшле документ конкурска килү белән шәхсән күрсәтелә);

г) зарури һөнәри белемне, квалификация һәм эш стажын раслаучы документлар:

нотариуста яки хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (хезмәт эшчәнлеге беренче мәртәбә гамәлгә ашырылган очраклардан гайре) яисә гражданның хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

белем һәм квалификация турында документлар, шулай ук граждан теләге

буенча өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки бирүне раслаучы документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документларның нотариуста яки хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

д) гражданның Россия Федерациясе дәүләт граждannар хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулаучы авыруының булмавы турында документ;

е) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты Указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында күздә тотылган бүтән документлар.

8.1. Җирле үзидарә органында үткәрелүче конкурста катнашырга теләк белдергән әлеге органда муниципаль хезмәт вазифасын биләүче муниципаль хезмәткәр гаризаны Комиссиягә бирә.

Бүтән җирле үзидарә органында үткәрелүче конкурста катнашырга теләк белдергән муниципаль хезмәткәр Комиссиягә гаризаны һәм тутырылган, имзаланган һәм үзе муниципаль хезмәт вазифасын биләгән җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формадагы анкетаны фотография белән тапшыра.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук саклау, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов